СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«МИЧУРИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«МИЧУРИН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

2023 елның 1 августыннан

№29

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 31 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 мартындагы 60-ФЗ номерлы федераль законнар, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы , «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 3 февралендәге 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 31 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 30.05.2017 №9; 17.11.2017 №26; 29.01.2018 №1; 19.09.2018 №20; 14.12.2018 №37; 20.03.2019 №9; 02.10.2019 №24; 12.01.2020 №2; 17.06.2020 №13; 13.08.2020 №15; 12.11.2020 №13; 26.03.2021 №2; 10.08.2021 №20; 28.04.2023 №18 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 1 статьяның 1.3 пунктында «, муниципаль берәмлекнең Сайлау комиссиясе рәисе» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 2 статьяның 2.1 пунктында «, Җирлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 5 статьяда:

5.3 пунктының 5 пунктчасында «, Җирлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.5 пунктының 4 пунктчасында «, Җирлекнең Сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 6 статьяда:

6.4 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«6.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәрнең урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатыннан, әлеге җирле үзидарә органының сайлап куелган профсоюз органында муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен алар тиешле вазифаны биләгән чорда яклый алмый.»;

6.6 пунктын төшереп калдырырга;

5) 7 статьяның 7.1 пунктында:

2 пунктчаның дүртенче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктчаның икенче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктчаның өченче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) җирле үзидарә органында ул муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән йә федераль законнарда башкасы каралмаган булса, турыдан-туры аңа буйсынган яисә аңа буйсынган өченче зат эшләре буенча вәкил булырга;»;

5 пунктчада «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, аларда» сүзләрен «анда» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктчада «, муниципаль берәмлекнең Сайлау комиссиясе», «, Сайлау комиссияләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

9 пунктчада «, муниципаль берәмлекнең Сайлау комиссиясе һәм аларның җитәкчеләре» сүзләрен «һәм аның җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

6) 7.1 статьяда:

1 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратыннан» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

10 пунктның 3 пунктчасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

7) 10 статьяда:

10.1.3 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, моңа хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклар керми;»;

10.2 пунктны түбәндәге эчтәлекле 10.2.4 пунктча белән тулыландырырга:

«10.2.4. Җирлекнең үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә Конкурс Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы арасында төзелгән кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турындагы килешүләр нигезендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү буенча Бердәм конкурс комиссиясе тарафыннан үткәрелә.»;.

8) 19 статьяда:

19.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 19.1.1 пунктча өстәргә:

«19.1.1. Муниципаль хезмәткәр «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтларын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында әлеге Нигезләмәдә һәм башка федераль законнарда билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен, шулай ук мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән очракта, аңа бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе дип танылa.»;

19.4.3 пунктының 1 пунктчасында «яисә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.4 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Президенты Администрациясенең вәкаләтле бүлекчәсе» сүзләрен өстәргә;

9) 20 статьяның 20.1 пунктындагы 4 пунктчасында «Россия Федерациясе Пенсия фонды;» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды» сүзләренә алмаштырырга;.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мичурин ис. поселок, Совет урамы, 26 йорт - административ бина, Совет урамы, 28 йорт - СДК бинасы; Яңа Сережкино авылы, Үзәк урам, 9 йорт -СДК бинасы, Үзәк урам, 15 йорт - мәктәп бинасы адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Мичурин авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Р.Ә. Иванова